ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2024 Балык Бистәсе штп. №349пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 09.10.2023 №343пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы заказчыларының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча ярдәм комиссия хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»11.06.2022 №160-ФЗ Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 09.10.2023 №343пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы заказчыларының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Заказчы җитәкчесе, контракт хезмәте җитәкчесе, контракт хезмәте хезмәткәрләре, контракт идарәчесе сатып алуларны гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шул исәптән заказчыга 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 23 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматны исәпкә алып, чаралар күрергә тиеш.»

1.2) Нигезләмәнең 5.5 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Комиссия әгъзасын алмаштыру комиссия төзү турында карар кабул иткән заказчы карары буенча гына рөхсәт ителә. Комиссия әгъзасы комиссияне төзү турында карар кабул иткән заказчыга әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктында каралган хәлләр барлыкка килү турында кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш. Комиссия составында әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктында күрсәтелгән физик затлар ачыкланган очракта, комиссияне төзү турында карар кабул иткән заказчы аларны кичекмәстән әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктында каралган таләпләргә туры килә торган башка физик затлар белән алыштырырга тиеш.»;

1.3) 6 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6.2.9 пункт өстәргә:

«6.2.9 Сатып алуларны гамәлгә ашырганда «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,шулай исәптән заказчыга 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 23 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматны исәпкә алып мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын күрергә .».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов